Каралды
Башлангыч сыйныф укытучыларының
мәктәп методик берләшмә
җитәкчесе ________ Тухбатуллина Э.М.
Беркетмә № 1
« 26 » август 2017 ел.

Килешенгән
Укыту эшләре буенча
директор урынбасары
________ Исмагилова Г,Т,.
"28" август 2017 ел

Раслыйм
Мәктәп директоры
________ Сабирзянова Г.Т..
Приказ № 71
« 28 » август 2017 ел

ь

ТР Сарман муниципаль районы МБГББУ"Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе"

# ТАТАР ТЕЛЕННӘН ӨСТӘМӘ ДӘРЕСЛӘР ӨЧЕН ЭШ ПРОГРАММАСЫ

**4 нче а сыйныфы**

**Салихова Нурия Миргасыйм кызы,** югары квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы

Каралды
Мәктәп педагогик советы
утырышы беркетмәсе №1
28 август 2017 ел

**2017 – 2018 нче уку елы**

## Аңлатма язуы

Татар теле фәненнән өстәмә сәгать буенча эш программасы Дәүләт стандартының Федераль компонентына нигезләнгән башлангыч мәктәпләрнең татар теле фәненнән үрнәк программасына, "Перспектив башлангыч мәктәп" концепциясенә һәм Федераль дәүләт белем стандартлары (ФГОС) таләпләренә, МБГББУ «Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе» белем бирү программасы, "Укыту курсы һәм предметының эш программаларын раслау һәм эшләү тәртибе структурасы" турындагы нигезләмә, мәктәпнең 2017-2018 нче уку елына базис укыту планына нигезләнеп эшләнде.

**Максаты:**

-укучыларда уңышлы аралашу сәләте булдыру-әйтмә һәм язма сөйләмне үстерү, кара-каршы сөйләшү осталыгы, монолог төзү һәм шулай ук гомуми культура күрсәткече булган грамоталы язу күнекмәләре булдыру, укучыларны тел фәненең төп мәгълуматлары белән таныштыру һәм шулар нигезендә аларның тамга символик һәм логик фикерләвен үстерү, татар теленең башка телләр белән берлектә дөньяның фәнни картинасын тудыруда катнашуы,аның милләте саклап калуда, халыкның, шәхеснең үзенчәлеген югалтмауда ышанычлы нигез, җәмгыятнең яшәешенә зарури шарт булуы турында күзаллау барлыкка китерү.

**Бурычлары:**

-балаларның сөйләм осталыгын, фикерләү сәләтен һәм иҗади хыялын үстерү, ана телендә аралашу максатына, бурычларына,шартларына туры килгән тел чаралары сайлый белергә, уй-фикерләрен төгәл белдерергә һәм әңгәмәдәше әйткәнне тәңгәл аңларга күнектерү

-телнең лексикасы,фонетикасы һәм грамматикасы буенча программада күрсәтелгән башлангыч белемнәрне үзләштерүгә ирешү

-укучыларда дөрес уку һәм язу күнекмәләре булдыру, диологта катнашырга һәм аларны зур, катлаулы булмаган монолог тибында төзеп әйтергә, тасфирлама, хикәяләү, фикер йөртү төрендәге кечкенә текстлар төзергә өйрәтү, уңышлы аралашу сәләте тәрбияләү.

**Предметның укыту планындагы урыны**

Программа 34 сәгатькә (атнага 1 сәгать) исәпләнгән.. УМК "Перспективалы башлангыч мәктәп"

**Универсаль уку гамәлләрен формалаштыруның көтелгән нәтиҗәләре**

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:**

- укучының өйрәнгән предметы (татар теле) буенча алган белем һәм күнекмәләре аның шәхес булып формалашуы өчен нигез була алу;
- уку һәм танып белүгә битараф булмау, тормышка актив караштa тәрбияләнү;
- ирешкән нәтиҗәләрнең баланың рухи-әхлакый үсешенә, сәламәт һәм хәвеф-хәтәрсез яши белүенә бәйле булу.

**Метапредмет универсаль уку гамәлләре:**

**Регулятив:**

- максатка ирешүдә үҗәтлек, авырлыкны җиңүгә әзер булу, авырлыкларны чишү ысулларын эзләүгә ихтыяҗ формалаштыру;
- план төзү һәм гамәлләр тәртибен ачыклау;
- ирешeләчәк нәтиҗәне алдан күрү;
- проблеманы чишүдә берничә вариант табу, аларны кулланып карау;
- үтәлгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү, уңышлылыгына бәя бирү;

- кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу.

**Танып-белү:**

- эшчәнлек барышын һәм нәтиҗәләрен тикшереп һәм бәяләп бару;
- сызым, схема, таблица, шартлы рәсем, план күчерү, үзгәртү, төзү;
- охшашлык һәм аермалыкларны аеру, чагыштыру;
- бербөтенне өлешләргә бүлү;
- аерып алынган нигез буенча объектларны тәртипкә салу;
- нәтиҗә чыгару;
- охшашлыклар урнаштыру;
- проблеманы кыска һәм ачык итеп әйтү;
- проблеманы чишү алымнарын хезмәттәшлектә табу.

**Коммуникатив:**

- укытучы, туганнар, әти-әниләр белән хезмәттәшлекне планлаштыру – катнашучыларның максатларын, вазифаларын үзара аралашу ысулларын билгеләү;
- дискуссиядә катнашу, сораулар формалаштыру, җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белү;
- проблеманы ачу, аны тормышка ашыру, үзара килешүгә ирешү;
- эшлекле партнерлы аралашу, төркемдә үзара ярдәм итешү;
- үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык, аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау.

**Предмет универсаль уку гамәлләре:**

- татар теле белеме тармакларына караган белемнәргә ия булу;
- татар теле буенча алган белемнәрне гамәлдә куллана белү;
- иҗади һәм мөстәкыйль фикерләү мөмкинлекләрен үстерү.

**Татар теленнән сәгатьләр бүленеше**

| № | Бүлекләр | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | **Орфограмма.** | **2** |
| 2 | Сүз. Телнең сүзлек байлыгы.Сүзнең лексик мәгънәсе | **6** |
| 3 | **Сүз төзелеше** | **3** |
| 4 | **Исем** | 4 |
| 5 | Фигыль | 2 |
| 6 | Сыйфат | 2 |
| 7 | Алмашлык | 2 |
| 8 | Сан | **1** |
| 9 | Рәвеш | **1** |
| 10 | Кисәкчәләр | 1 |
| 11 | Бәйлекләр | 1 |
| 12 | **Сүзтезмә** | 1 |
| 13 | Җөмлә. | 4 |
| 14 | Текст | **3** |
| 15 | Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту. | **1** |
|  | **Барлыгы** | 34 |

**Программа эчтәлеге**

**Орфограмма.**
Калын һәм нечкә сузыклар. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Тавышсыз хәрефләр. Парлы һәм парсыз яңгырау һәм саңгырау тартыклар.Калын һәм нечкә сузык авазлар. Е,я,ю хәрефләренең сүз башында һәм сузык авазлардан соң ике аваз белдергән очракларын танып белү һәм шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку, күчереп язу. Ъ, ь хәрефләренең аваз белдермәгәнлеген истә тоту, шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку. Сүзгә фонетик анализ ясау.Фонетика, морфология һәм синтаксистан үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү

**Сүз. Телнең сүзлек байлыгы.Сүзнең лексик мәгънәсе**

Сүз.Сүзнең лексик мәгънәсе. Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. Синонимнар. Антонимнар. Омонимнар. Аларның сөйләмдәге роле. Сүзнең күп мәгънәлелеген һәм күчерелмә мәгънәсен (фразеологик әйтелмәләр) куллану. Татар теленең сүз байлыгы. Дәреслекләрдәге сүзлекчәләрдән, сүзлекләрдән сүзнең аңлатмасын табып алу.

**Сүз төзелеше. Сүз ясалышы**

Морфология һәм аның состав өлешләре. Бер тамырдан берничә сүз ясалу, кушымчалар, аларның яңа сүз ясаудагы роле.

Тамырдаш сүзләр. Сүзләрнең ясалыш буенча төрләре (ясалма, кушма, парлы сүзләр).

**Морфология .**

Сүз төркемнәре

**1)Исем**Сүз төркемнәре төшенчәсе. Исем. Исемнең предметлык төшенчәсен белдерүе, аның җөмләдә ия булып килүе. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Исемнәрне тематик төркемләү.Исемнең берлек һәм күплек санда килүе. Күплек кушымчалары, аларның дөрес әйтелеше һәм ясалышы.Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Татар телендә килешләр һәм аларның сораулары. Сузык авазларга һәм яңгырау тартыкларга беткән исемнәрнең килешләр белән төрләнүе.

**2)Фигыль.**Фигыль сүз төркеменең мәгънәсе һәм сораулары. Фигыльнең барлык һәм юклык төрләре. Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Хикәя фигыльөч заманы: үткән заман, киләчәк заман, хәзерге заман.Фигыльнең заман формаларын дөрес ясау. Фигыльнең күп мәгънәлелеге.

**3)Сыйфат.** Сыйфатларның семантик төркемнәре. Сыйфат дәрәҗәләре (гади, чагыштыру, артыклык, кимлек дәрәҗәләре).

**4)Алмашлык.** Алмашлыкның мәгънә үзенчәлегенә –зат һәм предметны атамыйча, исемен генә алыштырып килүенә күзәтүләр. Зат алмашлыклары, килеш белән төрләнүе. Аларның җөмләләрне бер-берсенә бәйләүдәге роле.

**5)Кисәкчәләр.** *Да-дә, та-тә* кисәкчәләрен *-да/-дә, -та/-тә* кушымчаларыннан аеру. Кисәкчәләрне дөрес язу.

**6)Бәйлекләр.** Төрле килешләрдә исемнәрне һәм зат алмашлыкларын *белән, саен, шикелле, өчен, аркылы, таба, хәтле, каршы, кадәр, чаклы, бирле, соң, башка* бәйлекләре белән куллану.

**Синтаксис.**

Җөмлә. Хикәя, сорау, өндәү (боеру), тойгылы җөмләләр. Аларны текстта аера белү.

Җөмләнең әйтелү максаты буенча төрләренә карап, җөмлә ахырына тыныш билгесе кую. Җөмләнең баш кисәкләре . Язма сөйләмдә ия һәм хәбәрнең урыннары.

Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Җыйнак җөмләне, тиешле сүзләр өстәп, җәенкеләндерә белү, җәенке җөмлә эченнән баш кисәкләрне генә аерып чыгару.

Сүзтезмә

Сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аера белү, мәгънәләре, сораулар ярдәмендә җөмләдә сүзләр бәйләнешен ачыклау, сүзтезмәдәге ияртүче һәм ияртүче сүзләрне билгеләү.

**Бәйләнешле сөйләм**

Текстның темасын һәм төп фикере. Исемсез текстларның темасын билгеләү һәм исем кую. Төп фикерне темадан аера белү һәм аларны төгәлбилгеләү.

Текстның типлары: хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү. Аларның төп үзенчәлекләре.

Әзер яки күмәк төзелгән план буенча хикәяләү тибындагы текстны изложение итеп язу. Сюжетлы рәсемнәр һәм картиналар буенча укучыларның тормыш тәҗрибәсенә, күзәтүләренә, укыганнарына бәйле темаларга сочинениеләр язу. Телдән эш характерындагы текстлар төзү.

Сөйләм этикасы. Телдән һәм язмача чакыру, тәбрикләү.

**КАЛЕНДАРЬ - ТЕМАТИК ПЛАН**

| № | Дәреснең темасы | Үтәлү вакыты | | Эшчәнлек төре һәм формасы |
|---|---|---|---|---|
| | | план | факт | |
| **Орфограмма (2 сәг.)** | | | | |
| 1 | Авазлар һәм хәрефләр. | 02.09 | | Практик эш сүзләрдәге орфограммаларны танып, аларның язылышын кагыйдәгә нигезләнеп аңлату |
| 2 | Авазлар һәм хәрефләр. | 09.09 | | |
| **Сүз. Телнең сүзлек байлыгы. Сүзнең лексик мәгънәсе(6 сәг.)** | | | | |
| 3 | Сүзнең лексик мәгънәсе | 16.09 | | Лексик төшенчәсен аңлату,аңлатмалы сүзлекләр белән эш, хезмәтләрне бәяләү, төзәтү; татар теленең сүз байлыгы, сүзнең лексик мәгънәсе; лексик мәгънәгә туры килгән сүзләр табу |
| 4 | Алынма сүзләр. | 23.09 | | әйтелеш һәм язылыш, сүзлек запасын тулыландыру. |
| 5 | Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. | 30.09 | | Сүзләрнең төрле мәгънә белдерүе |
| 6 | Тотрыклы сүзтезмәләр. | 07.10 | | Фразеологик әйтелмәләрне сөйләмдә куллану |
| 7 | Омонимнар | 14.10 | | Парларда эш,омонимнарны табу |
| 8 | Синонимнар, антонимнар. | 21.10 | | Синонимнар, антонимнарга мисаллар китерә белү. |
| **Сүз төзелеше (3сәг.)** | | | | |
| 9 | Тамыр һәм кушымча. | 28.10 | | Парларда эш,сүз байлыгы; төрле телләрдән кергән сүзләр, кулланылу өлкәсе |
| 10 | Сүз ясагыч кушымчалар. Төрләндергеч кушымчалар. | 11.11 | | |
| 11 | Кушма сүзләр. Парлы сүзләр. Тезмә сүзләр. | 18.11 | | Парларда эш, парлы сүзләр, аларның ясалышы һәм дөрес язылышы Тезмә сүзләрне аеру, дөрес язу |
| **Сүз төркемнәре. Исем. (4 сәг.)** | | | | |
| 12 | Сүз төркемнәре. Исем. | 25.11 | | исем төшенчәсе, мәгънәсе, сораулары ялгызлык төшенчәсе, төркемнәре, |
| 13 | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. | 02.12 | | |
| 14 | Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. | 09.12 | | берлек һәм күплек сан формалары, берлек һәм күплек тартым кушымчалары |
| 15 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | 16.12 | | |
| **Фигыль (2сәг.)** | | | | |
| 16 | Хәзерге заман хикәя фигыль. Үткән заман хикәя фигыль. Киләчәк заман хикәя фигыль. | 23.12 | | Хәзергезаман хикәя фигыльнең белдерелеше, сораулары, ясалышы, юклык төр кушымчалары, сөйләмдә аларны аера белү |
| 17 | Боерык фигыльнең төрләнеше. | 13.01 | | |
| **Сыйфат (2 сәг.)** | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 18 | Сыйфат дәрәҗәләре. | 20.01 | | |
| 19 | Синоним һәм антоним сыйфатлар. | 27.01 | | |
| **Алмашлык (2 сәг.)** | | | | |
| 20 | Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше. | 03.02 | | Төркемдә эш,кагыйдәгә нигезләп,күнегүләр эшләү берлек сандагы зат ал-машлыкларын килеш белән төрләндерү; дөрес әйтелеш һәм язылыш |
| 21 | Сорау алмашлыклары. | 10.02 | | |
| **Сан (1 сәг.)** | | | | |
| 22 | Микъдар саны. Тәртип саннары. | 17.02 | | |
| **Рәвеш (1 сәг.)** | | | | |
| 23 | Телдә еш кулланыла торган рәвешләр, аларның дөрес язылышы. | 24.02 | | төрле сүзләр янында килүе; текстта рәвешне таба белү, куллану |
| **Кисәкчә (1 сәг.)** | | | | |
| 24 | Кисәкчәләр. | 03.03 | | Хаталар өстендә эш Белем һәм күнекмәләрне практикада куллану Сүзлекләр белән эшләү |
| **Бәйлекләр (1 сәг.)** | | | | |
| 25 | Бәйлекләр. | 10.03 | | Бәйлекнең җөмләдәге роле |
| **Сүзтезмә.(1 сәг.)** | | | | |
| 26 | Сүзтезмә. | 17.03 | | сүзтезмә төшенчәсе, аларны аера белү, сораулар кую |
| **Җөмлә. (4 сәг.)** | | | | |
| 27 | Җөмләнең баш, иярчен кисәкләре.Аергыч. | 07.04 | | Кагыйдәгә нигезләп күнегүләр эшләү хезмәтләргә бергәләп бәя бирү, хаталарны төзәтү; гади һәм кушма җөмлә төшенчәсен аңлату; тиңдәш кисәкләрне табу, чагыштыру, аеру, куллану |
| 28 | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре. | 14.04 | | |
| 29 | Эндәш сүзләр.Тест биреме. | 21.04 | | |
| 30 | Гади һәм кушма җөмлә. | 28.04 | | |
| **Текст. (3 сәг.)** | | | | |
| 31 | Текст.Тема.Текст өлешләре. | 05.05 | | Текстны уку,төп фикерне билгеләү әдәпле мөгаләмә таләпләренә туры китереп аралаша белү; |
| 32 | Сөйләм этикасы. | 12.05 | | |
| 33 | Хикәяләү, тасвирлау текстлары. | 19.05 | | Һәр абзацка исем кую, план төзү,эчтәлек сөйләү, орфограммаларны табу,эчтәлеген язу |
| **Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту. (1сәг.)** | | | | |
| 34 | Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту. | 26.05 | | Үтелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, тест һәм күнегүләр эшләү |

**Укыту –методик комплекты:**

1.Татар теле 1 кисәк, 2 кисәк дәреслек И.ХМияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова “ Мәгариф- вакыт” нәшрияты 2014 ел
2. И.Х Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова Методик кулланма “Мәгариф - вакыт” нәшрияты 2014 ел
3. Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар. 1-11 нче сыйныфлар Казан Татар. китап. нәшрияты 2011 ел
4. Татар теленнән диктантлар: Дүртьеллык башлангыч мәктәп. 1-4 сыйныфлар өчен: Укытучылар өчен кулланма/Я.Х.Абдрәхимова. - Казан: Мәгариф, 2009 ел.
5. 1-4 сыйныфлар өчен язма эшләр.Төзүчесе: М.А.Вәлиуллин. Казан 2009